МИНИСТЕРСТВО ЭКОНОМИКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ИКЪТИСАД МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**05.09.2022** Казан ш. **№331**

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан түләүсез нигездә коммерцияле булмаган оешма идарәсендә катнашу өчен эшкә алучы вәкиленең рөхсәтен алу тәртибен раслау турында

«Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясындагы 1 өлешенең 3 пунктының «б» пунктчасы нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында (алга таба – Министрлык) Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең түләүсез нигездә коммерцияле булмаган оешма идарәсендә катнашу өчен эшкә алучы вәкиленең рөхсәтен алуның кушымта итеп бирелгән тәртибен (алга таба – Тәртип) расларга.

2. Министрлыкның дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлегенә:

а) Министрлыкның дәүләт граждан хезмәткәрләрен әлеге боерыкның 1 пунктында күрсәтелгән Тәртип белән таныштыруны тәэмин итәргә;

б) әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция Министрлыгына билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә бирергә.

3. Министрлыкның Дәүләт мәгълүмат ресурслары һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән үзара хезмәттәшлек бүлегенә әлеге боерыкны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең Рәсми порталының Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы сайтында «Коррупциягә каршы тору» бүлегендә урнаштырырга.

4. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының түбәндәге боерыкларын үз көчен югалткан дип танырга:

«Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә коммерцияле булмаган оешмалар белән идарә итүдә бер генә кеше идарә итә торган башкарма орган сыйфатында катнашырга яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керергә эшкә алучы вәкиле тарафыннан рөхсәт бирү тәртибе турында» 2017 елның 18 июлендәге 231 номерлы;

«Татарстан Республикасы Икътисад министрының 2017 елның 18 июлендәге 231 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә коммерцияле булмаган оешмалар белән идарә итүдә бер генә кеше идарә итә торган башкарма орган сыйфатында катнашырга яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керергә эшкә алучы вәкиле тарафыннан рөхсәт бирү тәртибенә үзгәреш кертү турында» 2019 елның 29 апрелендәге 197 номерлы;

5. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – министр** **М.Р. Шаһиәхмәтов**

Татарстан Республикасы
Икътисад министрлыгы
2022 елның 05
сентябрендәге331 номерлы
боерыгы белән расланды

**Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең түләүсез нигездә коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашу өчен эшкә алучы вәкиленең рөхсәтен алу тәртибе**

1. Әлеге Тәртип, түләүсез нигездә коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә (сәяси партия, һөнәри берлек органы белән идарә итүдә, шул исәптән Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында оештырылган беренчел һөнәри берлек оешмасының сайланулы органы белән идарә итүдә катнашудан, съездда (конференциядә) яки башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, ширкәтенең (алга таба – коммерцияле булмаган оешмалар) гомуми җыелышында күчемсез милек хуҗасы буларак катнашудан тыш) катнашу өчен, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан (алга таба – граждан хезмәткәрләре, Министрлык) яллаучы вәкиленең рөхсәтен алу процедурасын билгели.

2. Әлеге Тәртип аларга карата эшкә алучы вәкиле Татарстан Республикасы икътисад министры (аның вазыйфаларын башкаручы зат) (алга таба – министр) булган граждан хезмәткәрләренә кагыла.

3. Граждан хезмәткәренең түләүсез нигездә коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашуы мәнфәгатьләр каршылыгына яки вазыйфаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликты барлыкка килү мөмкинлегенә китерергә тиеш түгел.

4. Коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашуга рөхсәт турындагы гариза (алга таба – гариза) әлеге Тәртипкә 1 нче кушымта (тәкъдим ителә торган үрнәк) нигезендә язма формада төзелә.

5. Гражданлык хезмәткәре Министрлыкның коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы затына (алга таба – җаваплы зат) коммерцияле булмаган оешма белән түләүсез идарә итүдә планлаштырылган катнашу башланганчы гариза бирә.

6. Гаризага идарә итүдә граждан хезмәткәре түләүсез нигездә катнашырга уйлый торган коммерцияле булмаган оешманың оештыру документының күчермәсе кушып бирелә.

7. Гаризаны Җаваплы затка тапшырганчы, гариза шәхсән танышу һәм, гражданлык хезмәткәре түләүсез нигездә коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашкан очракта, мәнфәгатьләр конфликты барлыкка килү мөмкинлеге турында фикер алу өчен түбәндәгечә җибәрелә:

а) Министрлыкның структур бүлекчәсе (идарәсе) башлыгы тарафыннан –

Татарстан Республикасы Икътисад министрының тиешле бүлекчә эшчәнлеген координацияләүче урынбасарына;

б) башка граждан хезмәткәре тарафыннан – граждан хезмәткәре Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен уза торган структур бүлекчә (идарә) башлыгына.

8. Җаваплы зат гаризаны ул кергән көнне әлеге Тәртипкә 2 нче кушымта нигезендәге форма буенча Коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу өчен гаризаларны теркәү журналында (алга таба – Журнал) теркәп куя.

Теркәү турындагы тамга белән гаризаның күчермәсе, Журналда имзасын салдырып, граждан хезмәткәренә бирелә, яисә тапшыру турында хәбәрнамә белән аңа почта аша җибәрелә.

9. Бүлек гаризаны алдан карауны һәм коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә гражданлык хезмәткәренең түләүсез нигездә катнашу мөмкинлеге (мөмкин булмау) турында дәлилләнгән бәяләмә (алга таба – дәлилләнгән бәяләмә) әзерләүне гамәлгә ашыра.

Дәлилләнгән бәяләмә әзерләгәндә, Җаваплы зат гариза тапшырган граждан хезмәткәре ризалыгы белән әңгәмә үткәрә һәм аңардан язмача аңлатмалар ала.

Дәлилләнгән бәяләмә әзерләү өчен, дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм оешмаларга өстәмә мәгълүмат алу максатыннан соратулар җибәрелә.

10. Дәлилләнгән бәяләмәдә түбәндәгеләр булырга тиеш:

а) гаризада бәян ителгән мәгълүмат;

б) гариза тапшырган граждан хезмәткәре белән әңгәмә вакытында алынган мәгълүмат (әңгәмә үткәрелгән очракта), шулай ук әлеге Тәртипнең 9 пунктында күрсәтелгән соратулар буенча алынган мәгълүмат (мондый соратулар җибәрелгән очракта);

в) гаризага язма аңлатмада граждан хезмәткәре тарафыннан бирелгән мәгълүмат (язма аңлатма алган очракта);

г) коммерцияле булмаган оешмага карата кадрлар, оештыру-техник, финанс, матди-техник яисә башка мәсьәләләр буенча карарлар кабул итү буенча граждан хезмәткәренең вәкаләтләрен анализлау;

д) граждан хезмәткәренең дәүләт граждан хезмәте турында һәм коррупциягә каршы көрәш турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән, вазыйфаи бурычларны намуслы үтәүне тәэмин итә торган тыюларны, чикләүләрне һәм бурычларны үтәвен анализлау;

е) гаризаны алдан карау нәтиҗәләре буенча дәлилләнгән нәтиҗә.

11. Гариза һәм дәлилләнгән бәяләмә гаризаны теркәү көненнән соңгы ун эш көне эчендә, ә әлеге Тәртипнең 9 пунктында күрсәтелгән соратулар җибәрелгән очракта – кырык биш календарь көн эчендә әлеге Тәртипнең 12 пунктында каралган карарларның берсен кабул итү өчен министрга җибәрелә.

12. Гаризаны карау һәм дәлилләнгән бәяләмә нәтиҗәләре буенча министр түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) граждан хезмәткәренә түләүсез нигездә коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашырга рөхсәт итәргә;

а) граждан хезмәткәренә түләүсез нигездә коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашуны тыярга;

в) Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Комиссиясенә (алга таба – Комиссия) карауга гаризаны һәм дәлилләнгән бәяләмәне гариза тапшырган граждан хезмәткәренең, коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә ул түләүсез нигездә катнашкан очракта, мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынуы булу-булмау предметына карап тикшерүгә җибәрергә.

13. Әлеге Тәртипнең 12 пунктындагы «б» пунктчасында каралган карарны кабул итү нигезе булып, граждан хезмәткәренең коммерцияле булмаган оешмага карата дәүләт идарәсе функцияләрен гамәлгә ашыруы һәм (яисә) дәүләт граждан хезмәте турында һәм коррупциягә каршы көрәш турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән, вазыйфаи бурычларны намуслы үтәүне тәэмин итә торган тыюларны, чикләүләрне һәм бурычларны үтәмәве (үтәмәү мөмкинлеге) тора.

14. Комиссия утырышында гариза һәм дәлилләнгән бәяләмәне карау нәтиҗәләре буенча әлеге Тәртипнең 12 пунктындагы «в» пунктчасы нигезендә министр гражданлык хезмәткәренә түләүсез нигездә коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашуны рөхсәт итәргә (тыярга) карар кабул итә.

15. Җаваплы зат, гаризаны карау һәм дәлилләнгән бәяләмә нәтиҗәләре буенча министр карар кабул иткән көннән алып, өч эш көне эчендә граждан хезмәткәренә министр кабул иткән карар турында аның имзасы белән, граждан хезмәткәренең вакытлыча эшкә сәләтсезлеген, ялда булу, хезмәт командировкасында булу вакытын, аның нигезле сәбәпләр аркасында хезмәттә булмавын санамыйча, язмача хәбәр итә, яисә министр кабул иткән карар турында гражданлык хезмәткәренә тапшыру турында хәбәр белән почта аша хәбәрнамә җибәрә.

16. Гариза, дәлилләнгән бәяләмә һәм гаризаны карау белән бәйле башка материаллар (алар булганда) граждан хезмәткәренең шәхси эшенә теркәп куела.

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2022 елның  05 сентябрендәге331 номерлы боерыгы белән расланды Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең түләүсез нигездә коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашу өчен эшкә алучы вәкиленең рөхсәтен алу тәртибенә 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы
икътисад министрына

______________________________________________

______________________________________________
(Ф.И.А., соңгысы – булганда), билгән вазыйфасы һәм структур

______________________________________________
бүлек, яшәү урыны адресы,

______________________________________________
телефон номеры)

**Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәре тарафыннан түләүсез нигездә коммерцияле булмаган оешма идарәсендә катнашу өчен эшкә алучы вәкиленең рөхсәтен алу турында**
**гариза**

«Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясындагы 1 өлешенең 3 пунктчасы нигезендә миңа коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашырга рөхсәт итүегезне сорыйм

______________________________________________________________________
(коммерцияле булмаган оешманың тулы исеме, юридик адресы, эшчәнлек төрләре, ИНН)

______________________________________________________________________

түләүсез нигездә ____________________________________ сыйфатында

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

Коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашу хезмәттән буш вакытта гамәлгә ашырылачак һәм вазыйфаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына яки мәнфәгатьләр конфликты барлыкка килү мөмкинлегенә китермәячәк.

_______________ _______________ ______________________
(дата) (имза) (фамилиясе, инициаллары)

Таныштым

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

(Татарстан Республикасы икътисад министры урынбасарының, структур бүлекчә башлыгының, гражданлык хезмәткәре түләүсез нигездә коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашкан очракта, мәнфәгатьләр конфликты барлыкка килү мөмкинлеге булу турындагы фикер)

___________________________________________________________________________

(вазыйфаның исеме, фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда)

________________________ _________________

(имза) (дата)

Гаризаларны теркәү журналында теркәлү номеры_____________

Гаризаны теркәү датасы 20_ елның «____» ___________

___________________________________________________________________________

(гаризаны теркәгән затның имзасы)

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2022 елның 05 сентябрендәге331 номерлы боерыгы белән расланды Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең түләүсез нигездә коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашу өчен эшкә алучы вәкиленең рөхсәтен алу тәртибенә 2 нче кушымта

# Коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашуга рөхсәт бирү өчен гаризаларны теркәү ЖУРНАЛЫ

| Т/б № | Гаризаны теркәү датасы | Гаризаның кыскача эчтәлеге | Гариза биргән затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булса), вазыйфасы | Гаризаны кабул иткән затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булса), вазыйфасы | Гариза күчермәсен алу (күчермәне алган, гариза биргән зат имзасы) яки гариза күчермәсен почта элемтәсе аша (адресны күрсәтергә) җибәрү турында тамга | Яллаучы вәкиле тарафыннан кабул ителгән карар турында билге | Граждан хезмәткәренә яллаучы вәкиле тарафыннан кабул ителгән карар хакында хәбәр итү турында билге |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| | | | | | | | |